УДК 821.512.145

*Л.Ш. Галиева*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ ПОЛЬША

Данная статья представляет собой обобщение известных фактов о жизни и деятельности Гаяза Исхаки в период его пребывания в Польше (1927–1939-е гг.), с целью наметить план для дальнейших исследований в этой области.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Польша, польские татары, Ю. Пилсудский, «Rocznik tatarski», «Wschod-Orient», организация «Прометей».

Күренекле әдип Гаяз Исхакыйның унбиш томлы әсәрләр җыелмасы, аның иҗаты һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге буенча мәкаләләр, җыентыклар дөнья күреп, диссертацияләр яклanса да, язучы һәм җәмәгать эшлеклесенең биографиясендә, бигрәк тә аның мөһаҗирлектәге чорына кагылышлы ачыкланып бетмәгән фактлар да бар. Әлеге мәкалә Г. Исхакыйның Польша дәүләте белән бәйле мәгълүматларны барлау ниятеннән язылды. Алар әдипнең әсәрләр җыелмасыннан, төрле мәкаләләрдән, хезмәтләрдән алынды. Төп максат – билгеле булганнарны җыйнау һәм анализлау аркылы киләчәктә алып барыласы эзләнү эшләренә нигез салу.

Г. Исхакыйның 1991 елда басылып чыккан «Зиндан» җыентыгында Һ. Мәхмүтов һәм Л. Гайнанованың күләмле мәкаләсе урнаштырылган. Әлеге язмадан язучының «Польша чоры» иҗаты һәм эшчәнлеге хакында түбәндәге мәгълүматлар бирелә: 1) Туган иленнән, үз халкыннан аерылгач, Г. Исхакый башта Харбин (Кытай), аннан Париж (Франция), Берлин (Германия), Варшава (Польша) һ.б. шәһәрләрдә яши. 1939 елның июль аенда Гитлер Германиясе Польшага һөҗүм башлагач, Польша хөкүмәте кушуы буенча, ул, язмаларын, архивын калдырып, ашыгыч рәвештә Төркиягә күчеп китә; 2) Г. Исхакый Харбин, Берлин һәм Варшавада яшәгәндә «Милли юл» дип исемләнгән нәшрият булдырып, татар эмигрант язучыларын шул тирәгә туплый һәм «Милли юл», «Яңа милли юл», «Безнең байрак» дигән газета-журналлар чыгара; 3) әдипнең «Идел–Урал» тарихи-публицистик китабы 1938 елда Варшавада поляк телендә дөнья күрә [Мәхмүтов, Гайнанова, б. 656–658]. Г. Исхакый әсәрләренең V томында Л. Гайнанова билгеле булганнарга шунысын да өсти: Г. Исхакый, Польшадан эмигрантлар оешмасы «Прометей» җитәкчеләре белән бергә, Варшавадан чыгып китәргә мәҗбүр була [Гайнанова, б. 8]. Тулырак мәгълүматны Г. Исхакыйның «Польшадан китү» язмасыннан беләбез: «1939 елның 6 сентябрь төнендә, сәгать уникеләрдә, Варшаваның Allee Ujazdovskідан ерак түгел, бер кечерәк урамның башында җыелышып, икенче егерме минутта юлга кузгалдык. Без – азәриләр

Әмин бәй Рәсүлзадә, Мирза Бала һәм Али Азәртәкин, Төньяк Кавказлы Сәгыйть Шамил, украин Смаль-Стоцкий, грузин Имнаидзе, Төньяк Кавказ казагы Билатти, шулай ук Төньяк Кавказлы Даут исемле егет, кырымлы Әдигә Шинкевич (Кырамал) һәм мин Гаяз Исхакый» [Исхакый, т. 13, б. 241]. Язучы биредә шулай ук бөтен әйберләре, киемсалымнары Варшавада калуын искәртә, аларны ул илдәшләре, башкалада укыган яшьләргә тапшырып китә [Исхакый, т. 13, б. 222].

Моннан тыш, шушы томның кереш сүзендә Л. Гайнанова тарафыннан түбәндәгеләр искәртелә: «Г. Исхакыйның Ватаныннан читтә яшәгәндә иҗат иткән барлыгы 11 әдәби әсәре мәгълүм. Шуларның икесе – “Ике ут арасында” драмасы һәм “Олуг бәйрәм” исемле хикәясе, әдипнең кызы Сәгадәт Чагатай төзүчегә язганча, әтисенең башка әйберләре белән бергә, Варшавада бер саклык банкысының кассасында кала, ул банкка бомба төшеп, бина җимерелә. Әмма Г. Исхакый үзе Варшавадагы архивының сакланып калу ихтималына беркадәр ышанган күрәсең. Лондонда курсларда укып йөргән кызы Сәгадәткә 1948 елның 26 октябрендә Истанбулдан язган хатында элекке танышлары булган нindидер Камиләгә сәлам күндерә һәм: “Ул Варшава белән язышамы? Минем өйдәге китапларның ни хәлдәгесен, янып бетеп-бетмәвен белмиме? Шуны сора әле”, – ди» [Гайнанова, б. 7].

Югарыда телгә алынган «Прометей» оешмасы хакында Г. Исхакый язганнардан: «Әле без, төрек-татар оешмалары һәр йирдә бергә, бер-беремезгә ярдәмләшеп, бер фикердә хәрәкәт итәмез. Дошманның көчлелеген аңлап, без бөтен рус кул астыннан котылыр өчен тартышкан халыклар белән якынлашырга телимез. Украина, Гөрҗестан, Кубань вә Дон казакларының истикъляль көрәшчеләре белән берегеп, «Прометә» исемле сәяси клублар төзедек. Шул ук исемдә Парижда французча бер мәҗмуга чыгарамыз. «Прометә»нең лозунгасы – Русияне милләтләр нигезендә бүлүдер» [Исхакый, т. 10, б. 177]. Әлеге оешма 1930 елда Польша хөкүмәте тарафыннан оештырыла һәм Тышкы эшләр министрлыгы каршында 1939 елга кадәр эшли [Исхакый, т. 10, б. 516]. Г. Исхакый – Варшавадагы «Прометей» клубының вәкиле булып торган [Исхакый, т. 10, б. 406]. Оешманың тоткан кыйбласы, максат-бурычлары, эшчәнлеге турында язучының тәфсилле «Прометә» мәкаләсен укып танышырга мөмкин [Исхакый, т. 12, б. 255–260].

Соңрак басылып чыккан мәкаләләрдә әдипнең Польша дәүләт эшлеклесе Ю. Пилсудский белән танышлыгы хакында мәгълүматлар китерелә. М. Хәсәновның Г. Исхакый әсәрләренең 1 томына язган кереш сүзенә мөрәҗәгать итик: Г. Исхакый Архангель сөргенендә чакта поляк революционеры (ә соңыннан күренекле дәүләт эшлеклесе) Ю. Пилсудский белән таныша, 30 нчы елларның икенче яртысында алар кабат очраша [Хәсәнов, 1998, б. 11], утызынчы

елларда Польшада «Варшау Прометее» дигән оешма белән җитәкчелек иткәндә ул Г. Исхакыйга ярдәм күрсәтә [Хәсәнов, 2000, б. 12]. Галимә Л. Гайнанова исә: «Польша хөкүмәтенең башлыгы, маршал Йозеф Пилсудский (1867–1935) Г. Исхакыйны Варшавага чакырып ала, аңа үз матбагасын оештыруда ярдәм итә», – дип язып чыга [Гайнанова, б. 7]. М. Сәхапов та әдипнең Пилсудский белән танышлыгына басым ясый: «Г. Исхакый 1907 елда Архангель губернасының Пинега шәһәрендә бергә сөргендә булган дусты маршал Юзеф Пилсудскийның шәхси чакыруы буенча Польшага килә һәм Варшава шәһәрендә төпләнә» [Сәхапов, 2006, б. 244–245]. Күрәбез, әлеге мәгълүматлар Г. Исхакый белән Ю. Пилсудскийның теге яки бу дәрәҗәдә аралашуы хакында сөйли. Әдип үзе исә Халидә Вафага «Мәгънәви васыятем кебек калсын» дип язган хатында мондый сүзләр җиткерә: «Ялгыз сәяси кыйммәтебезне аңлаган Ләһстан (Польша) хөкүмәте генә безгә аз-маз кулны суза ала. Аның аркасында мәмләкәттә күтәрелгән берлек байрагымызны йиргә иңдермибез» [Миңнегулов, 2004, б. 346]. Пилсудский, Дащинский кебек милли каһарманнарны Г. Исхакый гыйбрәт алырлык шәхесләр буларак бәяли [Исхакый, т. 10, б. 85].

Ф. Мусин хезмәтенә игътибарны юнәлтик. Галим Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге чорын тикшереп, әдипнең Ерак Көнчыгышка бару нияте турында хәбәр итә: «Польша властьларыннан Ерак Көнчыгышка командировка алу мәсьәләсе озак хәл ителми. Бу хакта без Г. Исхакыйның исем-фамилиясе билгесез бер поляк дәүләте чиновнигына рус телендә адресланган мөрәҗәгать-хатларыннан беләбез. Шул документларның берсендә, ягъни 1933 елның 6 июлендә язылганында, Г. Исхакый әлеге чиновникка “Господин капитан” дип мөрәҗәгать итә. ... Польша властьларының матди ярдәме белән оештырылган бу сәяхәт бер үк вакытта поляк разведкасының ныклы күзәтүе астына алына» [Мусин, б. 111–114]. Алга таба ул түбәндәгеләрне билгели: 1) әлеге ерак сәфәрдән әйләнеп кайтканнан соң, әдип төрки-татар конгрессын үткәрүне планлаштыра, Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгына багышлап үткәрелгән конгресс 1938 елның 4–6 февралендә Варшавада уза; 2) әлеге конгресс хакында аның 1938 елның февралендә Варшава радиосы аша ясаган чыгышы мәгълүм [Мусин, б. 137–139]. Милләт мәҗлесе юбилееның ни өчен нәкъ менә Варшавада уздырылуы турында Г. Исхакый «Яңа милли юл» журналында язып чыга: «Ләһстан әфкяре гомумиясенең безнең милли эшләребезгә хәер-хаһча каравы, сәяси вазгыятьнең мөсагыйд булуы бу мөһим истәлек бәйрәмебезне Варшавада ясауны алга сөрде» [Исхакый, т. 12, б. 233–234].

Г. Исхакый һәм Польша, Польша татарлары темасы беренче тапкыр галим Ә. Кәримуллин язмаларында күтәрелә. Аның «Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары» мәкаләсе 1994 елда

«Мирас» журналы битләрендә басыла [Кәримуллин, 1994, б. 196–199]. Бередә галим, билгеле булган мәгълүматларга таянып, берничә сорау куя: «Г. Исхакый кайчан Польшага барып чыккан, кайсы шәһәрләрдә яшәгән, нинди эшләр башкарган, кемнәр белән аралашкан, нәрсәләр эшләгән? дигән сорауларга конкрет, тулы җавап әлегә юк. Архангель губернасында сөргендә вакытта аның Пилсудский белән бергә булуын искә алалар. Польшага килгәнче һәм анда барып чыккач, Исхакый Польша Президенты булган шул Пилсудский белән очрашканмы, юкмы? Аның Польшага барып чыгуы шул танышлыкка барып тоташмыймы?» [Кәримуллин, 2005, б. 262]. Әдипнең Польшадагы эшчәнлеге турында ул вакытта билгеле булган мәгълүматлар түбәндәгеләр: 1) 1927–1939 елларда ул Берлин һәм Варшавада яшәп ала (Х. Миңнегулов фикере); 2) Г. Исхакый инициативасы белән 1928 елның 28 июнендә Варшавада «Идел-Урал» комитеты оештырыла; 3) әдип биредәге «Прометей» оешмасында актив эшләп килә; 4) биредә ул 1928 елның 23 декабрендә «Милли юл» исемендәге журнал чыгаруга керешкән һәм ул тора-бара «Яңа милли юл» исеме белән чыга башлаган [Кәримуллин, 2005, б. 262]. Әдәбият галиме Х. Миңнегулов фикерен Г. Исхакыйның «Польшадан китү» язмасында китерелгән сүзләр белән раслый алабыз: «Без, төрек илләренең милләтчеләре, ун-унике еллап элек бу дус илдә төзегән яңа милли оешмаларыбыз, милли азатлык өчен көрәш үзәкләребез дә шулай ук Польша белән бергә ут эчендә кала һәм җимерелә иде!..» [Исхакый, т. 13, б. 240].

Болардан тыш, Ә. Кәримуллин журнал укучыларын Г. Исхакыйның 1932 елда «Rocznik tatarski» («Татар елъязмасы») дип исемләнгән поляк басмасында дөнья күргән «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсе белән таныштыра. Әлеге язмадан аңлашылганча, Г. Исхакый Польшада яшәүче татарларның тарихы, мәдәнияте белән кызыксынган, аны аларның язмышы борчыган. Мәкаләне рус теленә галим Рифкать Йосыпов тәрҗемә итә. Соңрак ул аны «Польские страницы жизни Гаяза Исхаки» дип исемләнгән мәкаләсендә дә бастырып чыгара [Юсупов, с. 144–146]. Ә. Кәримуллинда китерелгән фактлардан тыш, Р. Йосыпов язмасыннан бер җөмләне өсти алабыз: «Краткое время в конце 1920-х гг. Г. Исхаки пребывал в Польше» [Юсупов, с. 144]. Әмма бу мәгълүматның кайсы чыганактан алынуы төгәлләштерелми. Галим Б. Гали «Польша татарларының милли бурычлары» мәкаләсенең «Милли юл» журналының 1929 елгы 12 нче санында урын алганын да искәртә [Гали, б. 56].

Л. Гайнанова 1999 елда басылып чыккан Г. Исхакый әсәрләренең икенче томында телгә алынган «Rocznik tatarski» журналы хакында өстәмәләр кертә: «Бөек Ватан сугышына кадәр Польшада поляк телендә поляк-литва татарларының тарихы, тормышы, мәдәнияте турында «Rocznik tatarski» («Татар

елъязмасы») дигән исемдә өч җыентык чыгып өлгерә (1932 елда – Вильнода, 1935 елда – Замощчта, 1938 елда – Варшавада)». 1932 елгы җыентыкта Г. Исхакый турында белешмә һәм аның «Польша татарларының милли мәсьәләләре» исемле мәкаләсе басылып чыга [Исхакый, т. 2, б. 458]. Әмма искәрмәләр авторы тарафыннан телгә алынган белешмә турында Ә. Кәримуллинда мәгълүмат юк.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗатын киң планда тикшергән галимнәрнең берсе – Х. Миңнегулов. Әлеге темага карата аның ике монографиясе дөнья күрә [Миңнегулов, 1999; Миңнегулов, 2004]. Алда саналган мәгълүматлардан тыш, соңгысында китерелгән фактларга тукталыйк: 1) Г. Исхакый бераз вакыт Польшаның Шәрык институтында эшләп ала; 2) 1937 елның башларында, бигрәк тә әдипнең туган ае – февральдә, Г. Исхакыйның иҗади эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу мәмләкәттән читтә яшәгән татарлар арасында киң күләмдә билгеләп үтелә. Юбилей тантаналарының иң зурысы 5 март көнне Варшавадагы Шәрык институтының зур залында уздырыла; 3) 1930 елда Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Азәрбайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли-азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора; 4) «Яңа милли юл» журналының 1931 елгы җиденче-сигезенче саннарының тышлыгында «Ләһстанда татар атлы гаскәрие», «Наполеонның татар гвардиясе», «Татар сугышчысы» кебек сурәтләр бар, алар «Ләһстан мөселманнарының милли музәханәләреннән алынган» (Г. Исхакый үзе биредә булганмы?); 5) Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗирлеккә дучар ителгән милләттәшләребез 1552 елгы кара көнне Хәтер көне, Матәм көне рәвешендә билгеләп үткәннәр. Мондый чаралар 1920–1930 елларда Польшада да узган; 6) Варшавада язучы һәм җәмәгать эшлеклесенең «Ислам мәмләкәтләрендә» дигән юл хатирәләренең бер өлеше язылган [Миңнегулов, 2004]. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби иҗаты киңрәк планда Ә. Сәхапов, Г. Зәйнуллина, И. Мансуровларның фәнни хезмәтләрендә чагылыш таба [Сахапов; Зайнуллина; Мансуров].

Варшавада яшәү дәверендә Г. Исхакый биредә милләтебезнең күренекле әдипләренә багышлап төрле кичә һәм чаралар үткәрүдә катнашкан, оештырып йөргән. Мисал өчен, Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу, «Тәрҗеман»ның 50 еллык бәйрәме һ.б. уңаеннан Г. Исхакыйның чыгышлар ясавы, шулай ук, Варшаваның «Прометей» клубында, Шәрык институтында лекцияләр укуы да мәгълүм.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге тарихчы, журналист һәм җәмгыять гыйлеме галимнәре – Б. Солтанбеков, И. Таһиров, Р. Гайнетдинов, Б. Гали, С. Исхаков, А. Мөбарәкҗанова, Г. Галәметдинов һ.б.ның хезмәтләрендә дә урын ала.Мисал өчен, галим

Р. Гайнетдинов үзенең «Деятельность татаро-башкирских эмигрантских организаций и центров в 1900 – начале 1930-х годов» дип исемләнгән диссертациясенең бер өлешен Г. Исхакый җитәкчелегендәге «Идел-Урал» оешмасының СССРга каршы алып барган антисоциалистик эшчәнлегенә багышлый. Әлеге хезмәттән шунысы билгеле: «Идел-Урал» «Бәйсезлек комитеты» Польша Генштабының II бүлеге тарафыннан финанслана һәм моның өчен әлеге хәрәкәт әгъзалары СССР һ.б. илләр хакында мәгълүмат тупларга тиеш була [Гайнетдинов, б. 15]. Б. Гали исә әлеге күренешне беренчел вакытта гына булуын ассызыклый [Гали, 41 б.].

Г. Исхакый һәм Польша темасы, әлбәттә, алга таба тагын да тирәнрәк өйрәнелергә тиеш. Биредә бары тик төп мәгълүматлар туплап бирелде. Билгеле булган фактлар шуны раслый: Г. Исхакыйның әлеге илдә алып барган эшчәнлеге төрле юнәлешле, ул күп кенә шәхесләр белән аралашуны күздә тоткан. Димәк, беренче чиратта, аларның исемләгән булдыру, эшчәнлекләре белән танышу, истәлек-хатирәләрне туплау һ.б. эшләрне башкару ихтыяҗы туа. Әлбәттә, бу юлда чит ил галимнәре хезмәтләренә таяну, алар белән элемтәгә керү дә сорала. Шул ук вакытта чит ил матбугатына игътибарны арттыру да зарур.

**Әдәбият**

*Гайнанова Л.* Төзүчедән // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 5 т. Казан, 2009. Б. 5–18.

*Гайнетдинов Р.Б.* Деятельность татаро-башкирских эмигрантских организаций и центров в 1900 – начале 1930-х годов: автореф. дис. ... канд. ист. наук. Казань. 1993. 20 с.

*Гали Б.Т.* Щедрый талант. Общественно-политическая деятельность и исторические взгляды Гаяза Исхаки. Казань: Унипресс, 2002. 96 с.

*Зайнуллина Г.И.* Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 2002. 24 с.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 10 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 527 б.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 12 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 471 б.

*Исхакый М.Г.* Әсәрләр. 15 томда. 13 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 335 б.

*Исхакый Г.* Әсәрләр. 15 томда. 2 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1909–1918). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 464 б.

*Кәримуллин Ә.* Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары // Безнең кардәшлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 261–270.

*Кәримуллин Ә., Нигъмәтҗанова А.* Гаяз Исхакый һәм Польша татарлары // Мирас. 1994. № 5–6. Б. 196–199.

*Мансуров И.С.* Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 2005. 28 с.

*Мәхмүтов Һ., Гайнанова Л.* Зарыгып көткән мирас // Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 636–660.

*Миңнегулов Х.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.

*Миңнегулов Х.* Исхакый мөһаҗирлектә. Казан: Таң–Заря, 1999. 84 б.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый: (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

*Сахапов М.Ж.* Творчество Гаяза Исхаки в период скитаний (1919–1954) = Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлек чорындагы иҗаты (1919–1954) = Gayaz Iskhaki the creative work at the period of warderings (1919–1954). Казань: Магариф, 2008. 294 с.

Сәхапов М.Җ. Бердәм агым. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 399 б.

*Хәсәнов М.* Татар ренессансының бөек каһарманы // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 2000. Б. 4–13.

*Хәсәнов М.* Татар ренессансының бөек каһарманы // Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.

*Юсупов Р.Р.* Польские страницы жизни Гаяза Исхаки // Вестник Челябинской государственной академии культуры и искусств. 2012. № 1 (29). С. 144–146.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*